СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
02 ноябрь 2023ел №1-30

## Концессион килешүне башка шартларда төзү мөмкинлеге турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы $4^8$ өлеше, «Концессион килешү төзү өчен конкурста катнашуга әзерлек турында гариза формасын раслау һәм концессион килешү төзү инициативасы белән чыгыш ясаучы зат белән концессион килешү төзү турында тәкъдим формасына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.09.2023 елның 16 сентябрендәге 1515 номерлы карары, «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль милкендә булган су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү турындагы тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең концессион килешү төзү инициаторы тәкъдим иткән башка шартларда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль милкендә булган су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү мөмкинлеге турында Карар кабул итәргә.
2. Әлеге карарга теркәлеп килүче Концессион килешү шартларын башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә килештерү максатларында сөйләшүләр уздыру тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга. (1 нче кушымта)
3. «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем төзергә һәм аның кушымта итеп бирелә торган составын расларга. .
4. Күрсәтелгән эшче төркемгә әлеге карарга кул куйган көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә концессион килешү шартларын тикшерү һәм аларны Тәртип нигезендә килештерү максатларында «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр формасында

сөйләшүләр уздырырга.
5. Башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә хәбәр итәргә.
6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 июнендәге № 3-26 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.
7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.
9. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /И.Н.Сәләхетдинов/

Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 02 ноябрь 2023ел, №1-30 карарына 1 нче Кушымта

Концессион килешү төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә концессион килештерү максатларында сөйләшүләр уздыру тәртибе

1. Килешүне төзү инициаторы тарафыннан тәкъдим ителгән башка шартларда Килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, концессия килешүе шартларын килештерү максатларында сөйләшүләр Килешү төзү инициаторының вәкаләтле вәкилләре катнашында эш төркеменең уртак киңәшмәләре рәвешендә (алга таба - Килешү) үткәрелә.

2.Килешүне төзү инициаторы тарафыннан тәкъдим ителгән башка шартларны килештерү турындагы карар эш төркеме тарафыннан кабул ителә һәм сөйләшүләрдә катнашкан барлык затлар тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә..

3. Сөйләшүләр барышында Килешү шартлары буенча килешүгә ирешелгән очракта, эшче төркем Килешү төзү инициаторына Килешүнең барлык катнашучылар тарафыннан имзаланган шартларын үз эченә алган беркетмәне җибәрә.

4. Сөйләшүләр барышында яклар Килешү шартлары буенча килешүгә ирешмәгән очракта, "Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге" ҖЧҖ концессия килешүен төзү инициаторы белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр үткәрү вакытын 3 айга озайтырга.

5. Сөйләшүләр барышында яклар Килешү шартлары буенча килешүгә ирешмәгән очракта, Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4.6 өлешенең 9 пункты нигезендә, килешү уздыру датасыннан алып 10 эш көне эчендә, килешүгә кул куелган беркетмә нигезендә килешү төзүнең мөмкин булмавы турында карар кабул итә һәм әлеге карарның күчермәсен Килешүне төзү инициаторына җибәрә.

6. Сөйләшүләр үткәрү нәтиҗәләре буенча беркетмә алганнан соң Килешү төзү инициаторы Килешү проектына, сөйләшүләр нәтиҗәләре буенча кабул

ителгән карарларны исәпкә алып, үзгәрешләр кертә һәм, беркетмәне алган датадан башлап, эш төркеменә Килешү проектын 10 (ун) эш көненнән артмаган срокта җибәрә.

7. Эш төркеме кертелгән үзгәрешләр белән Килешү проектын алган көннән башлап 3 (өч) эш көне эчендә тапшырылган документларны карый һәм Килешү проектын килештерү йә аны килештерү мөмкин булмау турында карар кабул итә. Эш төркеменең барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Килешү проектын килештерү мөмкинлеге турында эш төркеме кабул ителгән очракта, күрсәтелгән карар Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге Советына җибәрелә.

8. Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы эш төркеме беркетмәсе кергән көннән алып 3 (өч) эш көне эчендә Килешү проектын килештерү һәм Килешү төзү турында тәкъдимнәр кабул итү йә Килешү проектын килештермәү турында карар кабул итә.

Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 02 ноябрь 2023ел, №1-30 карарына 2 нче Кушымта

«Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем составы

1. Сәләхетдинов И.Н..- Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы
2. Хасанов Р.Р.- Мамадыш муниципаль районының «Халыкка хезмәт күрсәтү үзәге» генераль директоры.
3. Кашапова Д.Т.- Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Совет депутаты .